* ***Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы “Кадер урта гомуми белем мәктәбе”***

***9 класс, татар теле буенча дәрес фрагменты***

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы: Әюпова Алсу Фаит кызы

# Татар теленнән төп йомгаклау имтиханында изложение язу эзлеклелеге

* **Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.**
(татар халык мәкале)

* Дөреслеген тикшер!
* Карточка:
* 1) Көз иде.  Яңа гына кар төшкән.  Хуш исле печән салынган чанага ятып, урманга таба барабыз.  Тын урманны яңгыратып ат пошкыра.
* 2) Урман каравылчысы Вәлиәхмәт абый Себер шахталарында йөреп пенсиягә чыккан да, кайтып, урманны сакларга алынган. Тик аның кебек кырыс холыклы кешегә урман бик килешеп бетми иде. Урманның җанлы тормышы бар, ә тормыш ягымлылыкны, игътибарлы булуны, күзәтеп-белеп яшәгәнне ярата.
* 3)Без Вәлиәхмәт абый янына якынлашып килә идек, кинәт ул безнең күз алдында сәнәк очындагы печәнен ташлады да, бик каты селтәнеп, ниндидер җан иясен бәреп төшерде.  Мин кар өстендә аксыл чуар кош селкенүен күрдем.  Эчем жу-у итте.
* 4) Ә без, кешеләр, шул ятимнең хәлен аңламыйбыз.

* Дөреслеген тикшер!
* Карточка.

* *Ябалак кешеләргә ничек ярдәм итә?*
* Җавап: Синең якын дустың, беләсең килсә, урманны, йортыңны саклый.

* <u>Дөреслеген тикшер!</u>
* <u>Карточка. Орфографик хаталар</u>
* Берьюлы, үкенү-гаҗәпләнү, холык, игътибарлы, кадәр
* Вәлиәхмәт абзый, Сембер
* пошкыра, тормышы, йортыңны

* <u>Карточка. Пунктуацион хаталар. Тиешле тыныш билгеләрен куярга</u>
*
* Вәлиәхмәт абый нишләдең син ябалакны үтергәнсең бит дип кычкыруымны сиздем
* Җавап: - , , ! - .

* Дөреслеген тикшер!
* Карточка. Грамматик хаталар.
* 1)пенсиягә,     2) )чыелдавы      3) селкенүен     4) монда да
*
* Карточка. Сөйләм хаталары
*          1)ат пошкыра
*          2)аваз сала
*          3)колагыма элмәдем
*
* Карточка. Фактик хаталар
*    1)Хуш исле печән салынган чанага ятып, болынга таба барабыз.
*     2) - Вәлиәхмәт абый, бу кошны ябалак дип атыйлар

# Еш очрый торган хаталар

| Хата төре | Нинди хаталар еш күзәтелә? |
| --- | --- |
| орфографик | • сыйфатларда -рак, -рәк чагыштыру дәрәҗәсе кушымчалары язылышы;<br>• алынма сүзләр ( гарәп-фарсы сүзләре); парлы, кушма, тезмә сүзләр язылышы;<br>• ъ, ь билгеләре язылышы |
| пунктуацион | • кереш сүзләр янында тыныш билгеләре куелышы;<br>• ия белән хәбәр арасында сызык куелышы;<br>• аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре; туры һәм кыек сөйләм язылышы;<br>• кушма җөмләдә тыныш билгеләре куелышы. |
| грамматик | • ия белән хәбәрнең ярашуы;<br>• тиңдәш кисәкле җөмләләр төзелеше белән бәйле хаталар;<br>• фигыльләрдә заман формалары; җөмләдә сүз тәртибе;<br>• артык аффикслар куллану; |
| сөйләм хаталары<br><br>Фактик хаталар | • алмашлыкларны уңышлы кулланмау; тиешле стилистик бизәкле сүзләрне дөрес кулланмау;<br>• диалектальь лексика кулланылышы<br><br>• Даталар белән бәйле хаталар |

***Өй эше.***

***Мәрди Рәфыйковның "Ятим"тексты буенча сочинение язарга. Текст ахырында китерелгән "Хәзер уйлыйм: ябалакның берсе һәлак булгач, икенчесе ятим калган ич. Язгы көннәр якынлашкан саен, шул ятиме газаплана. Урманыннан инешкә кадәр парын эзләп килә. Кич җиттеме, аваз сала:***

***- Кайда син, яныма кил!***

***Ә без, кешеләр, шул ятимнең хәлен аңламыйбыз" дигән җөмләләр буенча, матур әдәбияттан 2 мисал, яки матур әдәбияттан 1 мисал, тормыштан 1 мисал кулланып, сочинение язарга.***


Барыгызга да
уңышлар телибез